wore the analogs of this headscarf as well. In general, towel-formed headscarfs can be seen in garments of Finno-Ugrian people and also among the peoples'garments of the Slavic group of ancient times. According to ethnographers, this kind of headscarves is a typical garment of Turkic women that live in Middle Asia. It must have been spread among people in the Middle Volga region very early as well. Over many years different versions of this headdress have appeared in each group [Mokhamadova, p. 19, p. 26].

On holidays malki Kryashen women wore *kashpau* on their heads. There are such variants of this word as *kashbau/ kashmau*. It is supposed to be a Turkic word, formed from morphemes *kash* and *bau (bag)*, so it means "a headdress that goes down to the brow level". At the same time different phonetic variants are explained in different ways. For example, according to Akhmetyanov, the part "mau" of the word "kashmau" can be related to the Chinese "women's hat"; and the part "pau" of the word "kashpau" can be related to the Persian "eyebrow (forehead) wear" [Akhmetianov, V. I, p. 386]. Kashpau was sewed in a form of a cut cone, the bottom part was decorated with big coins and the top – with smaller coins and beads. This kind of headdress used to be very popular among Kazan tatars. It is also can be found in garments of lambras (a group of Mishar Tatars) – kashpau, temnikovs (a group of Mishar Tatars) – kashbau, bashkirs – kashmau, Chuvashs – khushpu and besermyans – kashpu. All of this is grounds enough to conclude that kashpau used to be a widespread kind of headdress among Volga Region Turkic people [Baiazitova, 1997, p. 95].

Kryashen women's decorations were also mostly trimmed with coins, beads, pearls and gimp. Besides described above *chigacha, mangay tankase, mangay ukasy,* Kryashen women wore *muyensa, tushlek (izu, sakal), kasila / kasita, myytumar / muytomar / but'umar / buytymar / buydymar, syrga, chulpy, chachkap, belazek, baldak, zhozek / yozek* etc.

Women used to make neck-chest decorations themselves: they took a hard lining and sewed silver coins on it. Based on the lining form, these decorations can be divided into three parts: muyensa-formed, tushlek-formed and khasita-formed.

***Muyensa*** (in Chistopol' Kryashens' subdialect – **bun'sa**, in nagaybaks' – ***muysa***) is a neck-decoration made from rounded bottomed hard lining decorated with coins. This decoration was also called *tamaksa and muyenzhaka*. The last one also had a short form of *mun'zhaka*. Red beads were sewed to the top edge of muyensa, and seven big (1 rouble) coins were sewed on the bottom edge. In some groups women sewed additional 2-3 rows of smaller coins (50 and 20 kopecks) between beads and big coins. Muyensa is a widespread Kryashen women's decoration which is a part of a female daily outfit. Among Western Kryashen women muyensas with chains were also popular. According to art specialists, there is typological similarity between these muyensa's chains and Kazam muslim women's refined collar chains. [Mokhamadova, p. 21]. The Nagaybaks called a small collar chain "muysa", while the name "muyensa" was also used [Nagaibaks, p. 59, p. 61].

A rounded-bottomed big chest-decoration trimmed with coins and gimp, covering all the chest and sometimes hung below the waist was called differently. The Near-Kazan Kryashens called it *tushlek* (tush+lek). Here, tushleks decorated with gimp and gems like tatar muslim women's *izu* can be seen together with tushleks trimmed with coins. The Eastern Kryashens called the big chest-decoration trimmed with coins ***izu***. It was tied with chained muyensa. *Izu* and *tush* are considered to be ancient Turkic words [Akhmetianov, V, I, p. 295; Akhmetianov, V. II, p. 330]. Yelabuga Kryashens called this kind of decoration ***dawat***. They also had a tradition of wearing a chain over muyensa [Mokhamadova, p. 21]. The word dawat is not used in the modern Tatar language, but it exists in many dialects. It is supposed to be borrowed from Persian or Arabic languages and it has two meanings: the meaning «inkwell» of the word *dawat* can be found in many Turkic languages (Nogai, Kazakh, Karakalpak), the meaning "a wide ribbon laid crookedly on the shoulders" was used in neighbors' languages (Chuvash, Mari). The fact of these two meanings' relating to the same origin is explained by the following: ancient clerks used to fix their inkwells to a wide ribbon which they used to tie to the shoulders [Akhmetianov, v. I, p. 295; Akhmetianov, V. II, p. 241]. The "Tatar Big Dialectological Dictionary of Tatar Language" says that epy Nizhnekamsk Kryashens called the coined tushlek ***sakal;*** it is also mentioned that the word *dawat* was used in Nizhnekamsk and Chistopol' Kryashen's subdialect [Tatar telenen zur dialektologik suzlege, p. 556, p. 164]. According to F. Bayazitova, some representatives of Yelabuga and Near-Kazan Kryashens called the chest-decoration *sakal*. The same chest-decorations were also called sakal by Bashkirs [Baiazitova, 1997, p. 99]. In many languages, including Turkic ones, dif-

ferent phonetic variants of the word *sakal* are considered to be borrowed from the ancient mongol word that meant "multi-layered muyensa, many muyensas worn together" [Akhmetianov, V. II, p. 133]. As far as it can be noticed, there are many names of big coined chest-decorations and they are explained by researchers in different ways.

Another kind of chest-decoration related to ancient times is called ***khasita.*** The Kryashens used a lot of variants of its names, but basically they came down to the following two words: ***kasila / kasita, myytumarp / muytomar / but'umar / buytymar / buydymar***. This kind of chest-decoration used to be decorated by two-three rows of coins, it was a wide gimped ribbon which used to be worn so that one side lied on the shoulder and the other was passed under another arm. The variants *kasila / kasita* were changed from the Tatar literary word *khasita* and this word is typical for the Kryashens who live close to Kazan. In the Tatar literary language *khasita* is a chest-decoration worn on a dress and decorated with golden-silver coins and gimp [Tatar telenen anlatmaly suzlege, p. 640]. According to R. Akhmetyanov, *khasita* came from Arabic "kasyyda" that means "praising song in a special poetic form". He explains that "according to ancient customs, girls kept that praising poem with them as a talisman" [Akhmetianov, V. II, p. 388]. The words myytumar/but'umar are used in the speech of Yelabuga Kryashens, and in Pakshin village of Mamadysh district is has been saved as *buydumar*. Such designation of *khasita* as *but'mar, put'mar, put'yemar, put'ymar* is typical for Mishars'subdialects as well. It proves its ancientry and the fact that it used to be widespread. As for other Turkic languages, in Uzbek *buyyin tumor* means a decoration hung around the neck, in Nogai moytumar, moyun-tymar is a talisman. Southern Udmurts and Besermyans also have the word but'mar which means a chest-decoration as in Tatar subdialects as well [Baiazitova, 1997, p. 98].

As for hand jewelry, Kryashen women also liked to wear *belazeks* (bracelets) and rings. Flat engraved belazeks were very popular among them. Sometimes those had a hanging element made of small coins [Mokhamadova, p. 21]. Chistopol' Kryasnens named this kind of belazek ***cheltermale belazek*** [Baiazitova, Khaibullina, p. 189] and Nagaybacks – ***chalbarly belazek***. They also had *tankale belazeks* made of only coins. [Nagaibaks, p. 59]. Belazek is considered to be an ancient Turkic word [Baiazitova, Khaibullina, p. 189].

Kryashens liked to wear ***jozek/ yozek*** (rings) decorated with a large cornelian and just flat ***baldaks***. Sometimes women wore *baldaks* with two small coins fixed to the edge of the ring. In general, baldak has been known as Kryashens' church wedding attribute. As for rings decorated with gems, they are worn very seldom.

Speaking of Kryashen jewelry that required great skill ***oly syrga, chachkaby*** and big ***chulpys*** decorated with cornelian should be named. These kinds of jewelry were made in ancient style. Their smaller variants are popular in modern national style of Muslim women. As for Kryashen women, a big *syrga* used to be a part of headwear. Girls didn't wear them in their ears, but having tied it to a long ribbon made a turn around the ears and put them down along the cheeks [Mokhamadova, pp. 21–22]. It is known that in the Nagaybak language there was ***dyganak*** (not big syrga in a form of bow) and ***yorakle syrga*** (in a form of heart), and the big one was named just syrga [Nagaibaks, 58]. Syrga was a really popular piece of jewelry among Kryashen women. It was also named ***oly syrga, kechty*** (small) ***syrga***. Syrga is an ancient Turkic word, it can be seen in other Turkic languages as well: in the Bashkir language it is sounded like *hyrga*, in Altai – *syrga, yzyrga*, in Yakut – *ytyrga* [Baiazitova, 1997, p. 100].

Big ***chulpy***s are also considered to be a widespread piece of jewelry typical for Tatar women. There are plain and more complicated versions of them. Kryashen women don't let their braids hang down along their backs when they get married but turn thee braids around their heads and put malanchek on. That is why they seem not to need *chulpy*. But despite this, the big *chulpy* decorated with cornelian didn't disappear. They used to be fixed to the bottom edge of *chachkap* that was made from hard lining and decorated with coins. ***Chachkaby / chachkap*** (hair+encircle) used to be tied to the top of the braid and overlaid on it [Mokhamadova, p. 20]. Chistopol' Kryashens used the word ***chachtanka*** (hair+coin) or ***komesh tanka*** (silver coin) instead of chachkap. [Baiazitova, Khaibullina, pp. 190–191]. According to researchers, nagaybaks used the word ***chach bau***. By the end of the 20th century white kalpaks were worn more and more seldom, but *chach bau* was worn even with headscarves, the ends of which were tied under the chin. There is also such name as *chach bau of 3-5 branches* to denote the garment made of 3-5 long and narrow parts of fabric sewed on the end of chachkap and decorated with tiny coins [Nagaibaks, p. 56].

Having described Kryashens' garments and their names, we could not fail to notice that their

daily clothes names are similar to the names of the same clothes of other Tatar People' groups, that most of the names are commom Turkic terms (kulmak, yshtan, alzhapkych, zhaulyk, belazek, syrga, chigacha, chigalek, zhilkalek, kashpau, zhilan, chikman, tun, tolyp, burek, charyk / charik / charek, etc.),that there are words that are considered to be borrowed from other languages, for example, Persian (tastar, shawl, kalpak, daray), Arabian (takyya, kasila / kasita), Mongol (sakal), German (kamzul), also we could notice that some words' origin is explained differently (malanchek, suraka, chulpy, dawat, etc.) or cannot be explained (chukul / chukol, myytumar / muytomar / but'umar / buytomar / buydymar). It should be mentioned that pieces of female headwear are very peculiar and different. Depending on the Kryashens' locality, a lot of different versions of headdresses' names turned up (or appeared). There were different phonetic versions of the same word (for example, malanchek / malachlek / marachlek / balachlek, kashpau / kashbau / kashmau, etc.), or the same piece of clothes was named differently in different groups (muyensa, bun'sa, myysa, myyenzhaka, tamaksa; tushlek, izu, dawat, sakal, etc.). Many differences in the meaning and content, in ancient and modern meanings can be seen as well (*tugarak zhaulyk, ak zhaulyk, sakal, izu, myyensa, takyya, kalpak* etc.).

Having been separated from other Tatar people's groups and living closer to Chuvash, Udmurt, Mari and other peoples who accepted Christianity, the Kryashens have preserved their ancient Turkic-Tatar characteristics for many centuries, at the same time being influenced by their neighbors [Alkaia, Kirillova, pp. 155–178].

To sum up, it should be said that in Kryashens' speech ancient elements have been preserved. The lexis that is typical of only Kryashen subdialects is especially important. It includes relationship names, names of garments and jewelry, names of holidays and traditions, etc.

**References**

Akhmetianov, R. G. (2015). *Tatar telenen etimologik suzlege* [Ethimological Dictionary of the Tatar Language]. I tom (A-L). 543 p. Kazan, Magarif – Wakyt. (In Tatar)

Akhmetianov, R. G. (2015). *Tatar telenen etimologik suzlege* [Ethimological Dictionary of the Tatar Language]. II том (M-Ya). 567 p. Kazan, Magarif – Wakyt. (In Tatar)

Alkaia, E., Kirillova, Z. (2018). *Kreşin Tatar Türkçesi* [Kryashen Turkish Tatars]. (Dil, Tarih, Kültür). 670 p. İstanbul, Kesit Yay.(In Turkish)

Baiazitova, F. S. (1986). *Govory Kryashen v sravnitel'nom osveschenii* [Tatar-Kryashen Dialects in a Comparative Aspect]. 248 p. Moscow, Nauka. (In Russian)

Baiazitova, F. S. (1997). *Kerashennar. Tel uzenchaleklare ham iola izhaty.* [Kryashens. Particularities and Artistic Traditions]. 248 p. Kazan, Matbugat iorty. (In Tatar)

Baiazitova, F. S, Mukhametova, G. F. (2008). *Iazyk i kul'tuta: 'etnographicheskie issledovaniia po tatarskim govoram regiona iugo-vostochnogo Zakam'ia Tatarstana (Chistopol'skii, Menzelinskii, Krescheno-Tatarskii govory)* [Language and Culture: Ethnographic Studies of the Tatar Dialects in the South-Eastern Trans-Kama Region of Tatarstan (the Chistopolsky, Menzelinsky, Kryashen-Tatar Dialects)]. 284 p. Kazan', Alma-Lit. (In Russian)

Baiazitova, F. S, Khaibullina G. Kh. (2013). *Iazyk i kultura: etnolingvisticheskiie i etnokonfessional'nyie osobennosti govorov Zapadnogo Zakam'ia Tatarstana* [Language and Culture: Ethno-linguistic and Ethno-confessional Features of the Tatar Dialects in the Western Kama Region of Tatarstan]. 400 p. Kazan. (In Russian)

Belitser, V. N. (1951). *Narodnaia odezhda udmurtov.* – Moscow, izd-vo Akademii nauk SSSR. (In Russian)

Kirillova, Z. N. (2017). *Drevnetyurkskiie slova I zaimstvovaniia v govorakh kriashen kak otrazheniie narodnoi kul'tury v dialektnoq kartine mira* [Ancient Turkic Words and Borrowings in the Kryashen Dialects as a Reflection of Folk Culture in the Dialectal Picture of the World]. Izucheniie regional'noi kartiny mira v polikul'turnom obrazovatel'nom prostranstve: teoriia i praktika. Ministerstvo obrazovaniia i nauki Respubliki Tatarstan; Kazanskii federal'nyi universitet; pod.obsch.red. L. A. Mardiievoi, T. Yu. Schuklinoi, L. A. Usmanovoi. Pp. 65–71. Kazan', RITS "Shkola". (In Russian)

Kirillova Z. N. (2018). *Chuvashskiie I drevnetyurkskiie slova v govorakh kreschenikh tatar* [Chuvash and Old Turkic Words in the Dialects of the Baptized Tatars]. Iazykoviie kontakty narodov Urala i Povolzh'ia: sb. st. XI Mezhdunar. simpoziuma (Cheboksary, 21–24 maia 2018 g.) / sost. I otv.red. A. M. Ivanova, E. V. Fomin. Cheboksary, izd-vo Chuvash.univer., pp. 72–75. (In Russian)

Malov, S. Ye. (1951). *Pamiatniki drevnetiurkskoi pis'mennosti: teksty i issledovaniia* [Monuments of Ancient Turkic Writing: Texts and Studies]. 451 p. Moscow-Leningrad, izd-vo AN SSSR. (In Russian)

Makhmutova, L. T. (1979). *Nekotoryie materialy po leksike misharskogo dialekta tatarskogo iazyka* [Materials on the Vocabulary of the Mishar Dialect in the Tatar Language]. Issledovaniia po istoricheskoi dialektologii tatarskogo iazyka. Pp. 139 – 168. Kazan. (In Russian)

*Molkeievskiie kriasheny: sb.statei* (1993) [Molkeyevsky Kryashens: Collection of Articles].

Otv.red. D. M. Iskhakov. Kazan, IIALI ANT, Pp. 4– 25. (In Russian)

Mokhamadova, R. G. (2005). *Kerashen tatarlary kiyeme* [Kryashen Tatars' Clothing]. 159 p. Kazan, Suz. (In Tatar)

Mukhametshin, Yu. G. (1977). *Tatary-kriasheny. Istoriko-etnograficheskoie issleddovaniie material'noi kul'tury (seredina XIX – nachalo XX vv.)* [Tatars-Kryashen. Historical and Ethnographic Study of Material Culture (the mid 19th - early 20th centuries)]. 184 p. Moscow, Nauka. (In Russian)

*Nagaibaki (kompleksnoye izucheniye gruppy krezshenykh tatar-kazakov)* (1995) [Nagaybaks (A Comprehensive Study of the Group of Baptized Tatar-Cossacks)]. 147 p. Kazan, IIALI ANT. (In Russian)

Ramazanova, D. B. (2002). *Nazvaniia odezhdy i ukrashenii v tatarskom iazyke v areal'nom aspecte* [Names of Clothing and Jewelry in the Tatar Language in the Areal Aspect]. 354 p. Kazan, Master-Lain. (In Russian)

Ramazanova, D. B. (1991). *Terminy rodstva i svoistva v tatarskom iazyke*. [Terms of Kinship and Properties in the Tatar Language]. 192 p. Kazan, Tatar kn.izd-vo. (In Russian)

*Tatar telenen anlatmaly suzlege* (2005) [Explanatory Dictionary of the Tatar Language]. 848 p. Kazan, Matbugat iorty. (In Tatar)

*Tatar telenen zur dialektologik suzlege* (2009) [Big Dictionary of the Tatar Dialects]. 839 p. Kazan, Tatar kit. nashr. (In Tatar)

*Tatar khalyk soylashlare: ike kitapta: Berenche kitap* (2008) [Tatar National Dialects: In Two Books: Book One]. F. S. Bayazitova, D. B. Ramazanova, T. Kh. Khayretdinova et al. 463 p. Kazan, Magarif. (In Tatar)

*Tatar khalyk soilashlare: ike kitapta: Ikenche kitap* (2008) [Tatar National Dialects: In Two Books: Book Two]. F. S. Bayazitova, D. B. Ramazanova, T. Kh. Khayretdinova et al. 495 p. Kazan, Magarif. (In Tatar)

Vorob'iev, N. I. (1953). *Kazanskiie tatary* [Kazan Tatars]. 383 p. Kazan, Tatgosizdat. (In Russian)

# КЕРӘШЕН ТАТАРЛАРЫ СӨЙЛӘШЛӘРЕНЕҢ ЛЕКСИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**Зоя Николаевна Кириллова**,
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
zkirillova@yandex.ru.

**Әрҗан Алкая,**
Фырат университеты,
Төркия, Элазыг ш.,
ealkaya16@gmail.com.

Мәкалә татар халкының этноконфессиональ төркемен тәшкил итүче керәшен татарлары сөйләшләренең лексик үзенчәлекләрен тикшерүгә багышлана. Керәшеннәрнең күпчелеге Татарстан Республикасында яши, шулай ук аерым төркемнәре күрше Башкортстан, Удмуртия Республикаларында, Чиләбе, Киров һәм Самара өлкәләрендә дә урнашкан. Төрле территориягә таралып яшәүче керәшеннәр тел үзенчәлекләре ягыннан да, гореф-гадәтләре буенча да бер-берсеннән бик нык аерылып тора.

Керәшеннәрне, яшәгән территорияләренә, тел һәм сөйләм үзенчәлекләренә нигезләнеп, 5 төркемгә бүлеп карыйлар: казан арты, түбән кама керәшеннәре, нагайбәкләр, чистай һәм мәлки яки тау ягы керәшеннәре. Аларның беренче өчесе татар теленең урта диалектына кертеп карала, ә чистай һәм мәлки керәшен сөйләшләре исә көнбатыш диалектка карый дип билгеләнә. Мәкаләдә керәшен сөйләшләрендә татар теленең башка диалект һәм сөйләшләре белән уртак булган сүзләргә һәм аерым бер керәшен сөйләше яки урынчылыгы өчен генә хас булган атамаларга да күзәтү ясала.

Тикшеренүчеләр фикеренчә, керәшеннәр сөйләмендә борынгы элементлар сакланып калган. Керәшен сөйләшләре өчен генә хас булган лексик катлам аеруча әһәмиятле. Хезмәттә әлеге катламга кертеп карала торган туганлык атамалары, кием-салым һәм бизәнү әйберләре исемнәре тикшерелә.

**Төп төшенчәләр:** керәшен татарлары, сөйләшләр, лексик үзенчәлекләр, туганлык атамалары, кием-салым һәм бизәнү әйберләре исемнәре.

Керәшеннәр – Идел һәм Урал буйларында яшәүче татарларның үзенчәлекле бер төркеме. Алар христиан диненең православие юнәлешен тоталар. Тел һәм гореф-гадәтләре ягыннан да аерымлыклар күзәтелә.

Керәшен татарлары сөйләшләренең лексикасы, нигездә, татар халкының башка төркемнәре белән уртак. Шулай да бары тик керәшеннәр өчен генә хас булган үзенчәлекләр дә күзәтелә. Аларның күбесе рухи һәм матди мәдәнияткә караган сүзләрдә чагылыш таба. Татар халкының башка этнографик төркемнәреннән күпмедер дәрәҗәдә аерымланып яшәгәнлектән, керәшен сөйләшләрендә, татар әдәби теле белән тәңгәл килгән сүзләрдән тыш, язма истәлекләрдә урын алган һәм хәзерге төрки телләрнең кайберсендә кулланыла торган сүзләр дә сакланып калган [Кириллова, 2017, б. 66], [Кириллова, 2018, б. 72–73].

Керәшен татарларының өч сөйләше (казан арты, түбән кама һәм нагайбәкләр) татар теленең урта диалектына кертеп карала, ә ике сөйләш – тау ягы (мәлки яки подберезье) һәм чистай керәшен сөйләшләре исә көнбатыш диалектка карый. Кайда яшәүләренә бәйле рәвештә, керәшен татарлары сүзлек составында шул төбәктәге диалекталь лексика да урын ала. Мәсәлән, казан арты керәшеннәре сөйләше урта диалектның башка сөйләшләре белән уртаклык күрсәтә: адарыну ‘нәзер әйтү’, ардаклау ‘чистарту, аралау, чүптән аеру’, төс ‘сурәт, рәсем’, җурамалый ‘юри, шаяртып’, борлогу ‘борчылу, хәсрәтләнү’ һ. б. Түбән кама керәшеннәре сөйләшендә дә урта диалектның минзәлә сөйләше белән уртак сүзләр күзәтелә: инәй / нәнәй ‘әни’, алчак ‘ачык йөзле, ягымлы’, болагай ‘шапшак, җыйнаксыз’, тустаган ‘стакан яки чынаяк’, дурочмак ‘пәрәмәч’ һ.б. Нагайбәк сөйләшендә урта диалектның казан арты сөйләшләре, түбән кама керәшеннәре сөйләшенең бакалы урынчылыгы белән уртак лексика урын ала: тәберсен ‘үлгән кешене искә алып, ашамлыктан авыз итү’, печкәчә ‘ирнең сеңлесе’, җанагай ‘ирнең энесе’, аргыш кода ‘төп кода’ һ. б. Тау ягы керәшеннәре сөйләше көнбатыш (мишәр) диалектка кертеп каралса да, Ф. С. Баязитова күрсәткәнчә, анда урта диалектның тау ягы сөйләшләре белән уртак сүзләр дә урын ала: чәй түбере ‘чәй чүбе’, әнчек ‘эт’, чапчак ‘кисмәк’, киртләч ‘басма, баскыч’ һ. б.

Көнбатыш диалектның чистай һәм тау ягы керәшеннәре сөйләшләрендә мишәрләрнең башка төркемнәре белән уртак сүзләр дә кулланыла: тәләй ‘бәхет’, урынтын / ырынтын ‘яшерен’, иләмле ‘матур, ямьле’, гүчтинәч ‘күчтәнәч’, багалма ‘алма’, тенката ‘төне буе’; кырка ‘күркә’, кучат ‘әтәч’, басма ‘ситсы, тукыма’, ил ‘авыл’ һ.б. [Баязитова, 1997, б. 82–83], [Баязитова, 1986, б. 130–131].

Чистай һәм тау ягы керәшеннәре сөйләшләрендә кулланыла торган атна эчендәге көн исемнәре өлешчә мишәр диалекты һәм пермь татарлары сөйләше белән дә охшашлык күрсәтә. Мәсәлән, шундый уртаклыкларны аерып алып билгеләргә мөмкин: татар әдәби телендә һәм казан арты белән түбән кама керәшен сөйләшләрендә кулланылган дүшәмбе сүзе мишәр диалектында һәм чистай керәшеннәрендә – баш кен; сишәмбе – буш кен (тау ягы керәшеннәрендә бу көннәр чуваш алынмалары белән белдерелә: тунди кен һәм утлари кен); татар әдәби теле һәм мишәр диалектындагы чәршәмбе Пермь өлкәсе татарларында – кан көн, чистай һәм тау ягы керәшен сөйләшләрендә – шулай ук кан кен; әдәби телдәге пәнҗешәмбе мишәр диалектында, казан арты һәм түбән кама керәшен сөйләшләрендә – атна кич, пермь һәм чистай керәшеннәре сөйләшләрендә – кичатна, ә тау ягы керәшен сөйләшендә – кечатна; татар әдәби телендәге җомга мишәр диалектында – атна көн, чистай керәшеннәрендә – татар атнасы, ә тау ягы керәшеннәрендә – оло атна; шимбә көнне белдерә торган сүзләр сөйләшләрдә аерыла: мишәр диалектында – атнарас кен, пермь татарларында – коры көн, чистай керәшеннәрендә – атна кич, тау ягы керәшен сөйләшендә – атна көн; якшәмбе көнен белдерү өчен, тау ягы керәшеннәрендә һәм мишәр диалектында – урыс атнасы термины һәм пермь татарлары сөйләшендә, бераз гына үзгәртелеп, урыс атна көн атамасы кулланыла, чистай керәшеннәрендә исә моның өчен, казан арты һәм түбән кама керәшен сөйләшләрендәге кебек үк, атна көн термины урын ала [Баязитова, 1997, б. 83].

Керәшеннәрнең барлык сөйләшләрендә дә диярлек Пермь татарлары белән лексик уртаклык күзәтелә. Мисал өчен, шундый гомуми сүзләрне күрсәтергә мөмкин: алчүпрәк ‘алъяпкыч’, артылу ‘тулып ташу’, аңгару ‘аңлау, төшенү’, басмак ‘басма, баскыч тактасы’, бертын ‘азрак, бераз’, калдык ‘соңгы, актык’, кавын ‘кабак’, който ‘начар, әйбәт түгел’, сону ‘сузу’, чара табак ‘зур агач табак’ һ.б. [Баязитова, 1986, б. 130].

Татар теленең башка диалект һәм сөйләшләре белән уртак булган сүзләрдән тыш,

галимнәр тарафыннан һәр керәшен сөйләше һәм урынчылыгы өчен генә хас булган атамалар да аерып чыгарыла. Мәсәлән, казан арты керәшеннәре сөйләшенең мишә буе урынчылыгында – богол ‘печән кибәне’, икенче чабым ‘кәлшә, курпы’, балтыр ‘куныч, балак’ [Татар халык сөйләшләре: Беренче китап, б. 88]; ташкирмән урынчылыгында – гомбакты ‘көнбагыш’, гөбө сөтө ‘май әйрәне’, тыуган-игәч ‘туган-тумача’, салмаклы ‘авыр’, ардаклы ‘кадерле’; пакшин урынчылыгында – әрәпә (гар. гәрәфә) ‘үлгән кешеләрне искә алу көне’, этей агай (башка керәшеннәрдә – урсәти / үрсәти) ‘баланы чукындырганда, икенче «әти» итеп билгеләнгән ир-ат’, әней түти ‘баланы чукындырганда, «әни» итеп куелган хатын-кыз’, җәйләү ‘чынаяк тәлинкәсе’, тыккыч ‘бөке’, почкак юрган ‘корама юрган’; нократ буе урынчылыгында – чүб итеү (башка керәшеннәрдәге чүк итү) ‘кырга чыгып, корбан чалып, теләк теләү’ (хәзерге вакытта күбрәк махсус бәйрәм атамасы буларак кулланыла), әпрән ‘әрекмән’, җисерләнү ‘азаплану, тырышу’ һ. б.; кама буе урынчылыгында – пуҗым ‘йорт урыны’, куныч (башка керәшен сөйләшләрендә – балтыр, балак), кәсилә (башкаларда – кәситә, түшлек) һ.б.; шушма буе урынчылыгында – тоҗом ‘гөслә кылы’, бутый ‘ботка’, дурчый / дурочмак ‘бәрәңге пәрәмәче’, күзей ‘күзикмәк, кыстыбый’, алма ‘бәрәңге’, багалма ‘алма’, чәй токмачы ‘кош теле’, тувар ‘мал, хайван’, чакыру ‘кычкыру’, тәтә ‘апа’; кукмара урынчылыгында – майлы ботка бәйрәме ‘май чабу, масленица’, коро тоту ‘ураза тоту’, коро май ‘үсемлек мае’ [Татар халык сөйләшләре: Беренче китап, б. 89–92] һ. б. сүзләрне күрсәтергә мөмкин.

Түбән кама керәшеннәре сөйләшенең алабуга урынчылыгы өчен генә хас сүзләргә очтомак ‘оҗмах’, чүкәтә ‘туп’, тәбәшәк ‘тәбәнәк’, нәнәй / мама ‘әни’, кабак ‘аракы; кибет’, җисерләнү ‘азаплану’, җүт ‘эндәшми торган кеше’ һ.б.; чаллы урынчылыгында – сыпкы ‘пычрак’, пычкы җармасы ‘пычкы чүбе’, абалану ‘сөртенү’, абрау ‘коткару’ һ.б.; зәй урынчылыгында – паҗма ‘йорт урыны’, кәйә ‘начар’, савапый ‘зират’, бусан ‘төклетура’, кубыну ‘китү, күченеп китү’ һ.б.; бакалы урынчылыгында – кылык тавык ‘кыртлый торган тавык’, тупыракса ‘чорма’, тирәзә налишнигы ‘тәрәзә йөзлеге’, сөрән сугу ‘Пасха бәйрәме көнне, атка атланып, йомырка җыеп йөрү’ [Татар халык сөйләшләре: Беренче китап, б. 109–112] һ. б. диалекталь сүзләрне кертергә мөмкин.

Тау ягы керәшеннәре сөйләшендә генә табыла торган сүзләрдән түбәндәгеләрне әйтергә була: җегертмә ‘тәгәрмәч’, кисрәнү ‘тетрәнү’, асу ‘файда; игелек’, мынгый ‘моңлы’, чәчәк ‘яфрак’, өтү ‘кабартма’, күзлек ‘көзге’, кабарту ‘калач, күмәч’ [Татар халык сөйләшләре: Беренче китап, б. 121], барнаска ‘уймак’, тулак ‘тула’, җатка китү ‘күршедәге башка авылларга кичке уенга китү’ [Баязитова, 1986, б. 47] һ. б.

Галимнәрнең күрсәтүенчә, керәшеннәр сөйләмендә борынгы элементлар сакланып калган. Керәшен сөйләшләре өчен генә хас булган лексик катлам аеруча әһәмиятле. Әлеге катламга туганлык атамалары, кием-салым һәм бизәнү әйберләре исемнәре, бәйрәм һәм йола атамалары һ. б. керә. Шуларның кайберләренә тукталып үтәргә телибез.

**Туганлык атамалары**

Әлеге тематик төркемгә караган сүзләр телләрнең бик борынгы катламын тәшкил итә. Төрки телләрнең күбесе өчен уртак булган туганлык атамалары керәшен сөйләшләрендә дә сакланып калган. Аларны, гадәти бүленеш буенча, кан кардәшлеген белдерә торган һәм өйләнешү нәтиҗәсендә барлыкка килгән кардәшлекне аңлатучы сүзләргә бүлеп карарга мөмкин.

***Кан кәрдәшлеген белдерә торган туганлык атамалары***ннан әни, әти, әби, бабай сүзләре татар әдәби теле белән тәңгәл килә, шул ук вакытта аларның төрле сөйләшләрдә башка вариантлары да урын ала. Мәсәлән, әни сүзе әней, инә, инәй, нәнәй, нәнәү, мама, мамау, әнәү, айнау, ан’н’у кебек төрләрдә очрый. Шулардан иң күп кулланылганы – әней формасы, шулай ук яшьләр арасында рус теленнән кергән, ләкин басымы соңгы иҗеккә күчерелгән мама сүзе дә еш урын ала. Инә, нәнәй сүзләре нагайбәк һәм Башкортстанның Бакалы районы керәшеннәре өчен хас, шулай ук нәнәй сүзе, Ф. Баязитова күрсәткәнчә, Алабуга районы, Зәй тирәсендә яшәүче керәшеннәр сөйләшендә, казан арты сөйләшләренең кайбер төркемнәрендә дә кулланыла. Моннан тыш, инә, нәнәй сүзләре татар теленең минзәлә, бөре, гәй, эчкен сөйләшләрендә дә шул ук формада урын ала һәм алар борынгы төрки ана сүзенең фонетик вариантлары булып торалар [Баязитова, 1997, б. 89]. Нәнәй сүзе башкорт теле өчен дә хас. Нагайбәк сөйләшендә исә бу сүзнең нәнәү варианты да кулланыла [Татар халык сөйләшләре: Беренче китап, б. 138]. Тау ягы

керәшеннәре сөйләшендә әни сүзе белән бергә әнәү, айнау, ан’н’у [Баязитова, 1997, б. 89], ән’ү, ән’н’ү, ан’оу, эйн’оу, ән’әү [Молькеевские кряшены, б. 128] формалары да урын ала.

Әти сүзен белдерү өчен, төрле керәшен сөйләшләрендә алдагы сүзләр кулланылырга мөмкин: әтей, папа, папау, тәтәй, айтоу, эйчоу, әтәү, ат’т’у һ. б. Шулардан иң күп урын алганы – әтей формасы. Рус теленнән алынган папа сүзе, мама кебек үк, күбрәк яшьләр һәм балалар телендә кулланыла һәм басымны соңгы иҗеккә куеп әйтелә. Папау варианты исә нагайбәк керәшеннәрендә генә очрый. Ф. Баязитова күрсәткәнчә, Кукмара районының ике авылында һәм Чистай районы керәшеннәрендә әти сүзе урынына тәтәй сүзен кулланып сөйләүчеләр дә бар. Рус теле диалектларында да тятя – әти мәгънәсен белдерә торган сүз. Бары тау ягы керәшеннәреннән генә диалектологлар тарафыннан әти сүзе өчен гаять күп төрле вариантлар: айтоу, эйчоу, әтәү, ат’т’у [Баязитова, 1997, б. 90], әчү, әтү, әтчү, ачу, әйчү, әчоу, эйчоү, эйчау [Молькеевские кряшены, б. 128] язып алынган.

Дәрия Рамазанова фикеренчә, икеләтелгән тартыклы әннә, эттә атамалары татар теленең казан арты һәм каргалы сөйләшләре өчен дә, шулай ук чуваш, төрек, балкар телләре, азәрбайҗан диалектлары өчен дә хас. Әнәү, ан’оу, ан’н’у, ән’ү кебек вариантлар -ау/-әү формалы чакыру килеше тараюның төрле этапларын чагылдыра. Т~ч тәңгәллеге исә Идел буе Болгар дәүләте кабер таш язмаларында да, пермь татарлары сөйләшендә дә күзәтелә. Галимә шулай ук «ат’т’у, атчу вариантлары борынгы төрки аča ‘туган’, ача/эҗе ‘өлкән туган’ сүзләреннән калган күренеш булырга мөмкин» дигән фаразлавын да белдерә [Молькеевские кряшены, б. 129].

Татар әдәби телендәге кебек үк, керәшеннәрдә дә бабай һәм әби / әбей сүзләре урын ала. Әнинең әнисен һәм әтисен белдерү өчен, җырагәбей (җырак+әбей), җырак бабай атамаларын кулланалар. Гомумән, әнинең туганнарын белдергән сүзләр җырак сүзе белән ясала. Безнең фикеребезчә, бу сүз гаиләнең әти йортында яшәве нәтиҗәсендә, әни ягы туганнарының читтә, еракта булуы нигезендә барлыкка килгән булырга тиеш. Кайбер урынчылыкларда әтинең әти-әнисенә үз бабай һәм үз әбей дип эндәшү дә күзәтелә. Әдәби телдәге кебек үк, керәшеннәрдә дә әбей һәм бабай сүзләре кан кардәшлеген белдерү өчен генә түгел, өлкән яшьтәге кешеләргә эндәшкәндә дә кулланыла.

Абый мәгънәсен белдерү өчен, дәдә яки дәдәй сүзләре, тау ягы керәшеннәрендә – дад’у, д’әд’у, дейдау формалары урын ала. Дәдә сүзе татар теленең мишәр диалекты сөйләшләрендә дә кулланыла һәм чыгышы белән төрки сүз дип карала [Махмутова, б. 142], [Баязитова, Мухаметова, б. 66], [Баязитова, 1997, б. 90]. Дәдә термины угыз телләренә дә (азәрбайҗан телендә – дәдә, төрекчә – dede, төрекмән телендә – дәде), шулай ук көнчыгыш славян телләренә дә хас. Д. Рамазанова фикеренчә, бу сүзнең мишәр һәм керәшен сөйләшләрендәге активлыгы рус теленең йогынтысы белән дә аңлатыла [Рамазанова, 1991, б. 192], [Баязитова, Хайбуллина, б. 170]. Тау ягы керәшеннәрендә, әнинең абыйсын яки энесен белдерү өчен, кукки сүзе урын ала. Әлеге сүз чуваш телендә шул ук мәгънәдә кулланылган кукка сүзеннән алынган [Молькеевские кряшены, б. 130].

Апа сүзе урынына керәшен сөйләшләрендә түти, тута, түтәй, тәтәй, тәтә-апа кебек сүзләр урын ала. Тута / түти / түтәй сүзләре иске татар әдәби телендә дә актив кулланылганнар. Тау ягы керәшеннәре сөйләшендә, апаны белдерү өчен, т’ит’у, тейчоу [Баязитова, 1997, б. 91], т’иту, т’итыу, чичу вариантлары күзәтелә. Әлеге атамалар, чуваш телендәге аппа, акка сүзләреннән аермалы буларак, татар теленең төрле сөйләшләрендә кулланылган тәтә / түти / тута вариантлары белән охшашлык күрсәтәләр, касыйм сөйләшендә, кайбер керәшен сөйләшләрендә һәм көнчыгыш диалектта шул ук мәгънәдә урын алган чичә сүзе исә [т] авазының нечкә әйтелүен һәм тамыр тартыкларның тәңгәллеген дә аңлатырга ярдәм итә [Молькеевские кряшены, б. 129–130].

Әти яки әнинең иң өлкән ир туганына эндәшү өчен – ак дәдәй, ә кыз туганына ак түти дип әйтү киң таралган. Нагайбәкләрдә ак түти урынына оло тәтәү сүзе кулланыла [Баязитова, 1997, б. 91]. Моннан тыш, әнинең абый яки энеләренә – җырак дәдәй, апа яки сеңелләренә җырак түти дип эндәшү дә кабул ителгән. Дәдәй яки түтиләр күп булса, аларны берберсеннән аеру өчен, күп төрле атамалар бирелергә мөмкин: матур түти, чибәр түти, алма түти, апай (яхшы мәгънәсендә – *З. К.*) түти, апай дәдәй, оло түти, оло дәдәй, кечкенә түти, кечкенә дәдәй һ. б.

Дәдәй һәм түти сүзләре, татар әдәби телендәге абый һәм апа кебек үк, кан кардәшне белдерү өчен дә, шулай ук эндәшүче яисә сөйләүчедән өлкәнрәк булган ир-ат яки хатынкызны аңлату өчен дә кулланыла.

Борынгы төрки телдә дә актив кулланылган [Малов, б. 359], хәзерге төрки телләрдә исә ага / ака / акы вариантларында билгеле булган һәм өлкән ир туганга һәм, гомумән, олырак яшьтәге ир-атка хөрмәт белән эндәшү сүзе булып хезмәт иткән ага сүзе керәшен сөйләшләрендә дә шул ук мәгънәләрдә кулланыла. Нагайбәк сөйләшендә һәм казан арты сөйләшләрендә сирәк очракларда агачай сүзе дә урын ала. Алабуга керәшеннәрендә сирәк кенә шулай ук аба сүзе дә кулланыла. Бу сүз башка төрки халыкларда (мәсәлән, башкорт, кыргыз, төрекмән, хакас, алтай теле һәм диалектларында) да өлкән ир туганны белдерә [Баязитова, 1997, б. 90].

Кече кардәшләрне белдерү өчен, әдәби телдәге кебек, эне, энекәш яки сеңел, сеңелкәш сүзләре кулланыла. Ләкин аларга мөрәҗәгать иткәндә, гадәттә, исеме белән генә әйтелә.

Керәшен сөйләшләрендә шулай ук бала, бәби, кыз, малай кебек сүзләр дә татар әдәби теле һәм күпчелек сөйләшләре белән уртак. Мишәр диалектына кертеп каралган сөйләшләрдә генә аларның кайбер башка вариантлары да урын ала. Мәсәлән, бала сүзеннән тыш, тау ягы керәшеннәрендә ылан / лан сүзе дә, бала-чага мәгънәсендә – ыланшак (углан > ылан + борынгы төрки ушак – вак) сүзе дә киң таралыш алган. Уланшак сүзе пермь татарларында да кулланыла. Башка төрки телләрдән азәрбайҗан телендә ушаг – бала; төрек телендә uşak – яшүсмер, егет; кыргыз телендә ушак – вак, улан-ушак // улан – егет, оглан-ушак – балалар һ.б. Малай/малый сүзе дә мишәр диалектындагы керәшен сөйләшләрендә еш кына, сергач, чүпрәле, тау ягы, мордва-каратай сөйләшләрендәге кебек үк, бала мәгънәсендә кулланыла. Ул яки кыз сүзләре ярдәмендә баланың җенесенә төгәллек кертелә: ул малый ‘ир бала’, кыз малый ‘кыз бала’. Ыланшак кебек үк, бала-чага мәгънәсендә малайшак сүзе дә кулланылырга мөмкин. Татар әдәби теленә малай сүзе рус телендәге малой, малый сүзләреннән алынган дип санала [Молькеевские кряшены, б. 131–132; Әхмәтьянов, II т., б. 14].

***Өйләнешү нәтиҗәсендә барлыкка килгән кардәшлекне белдерә торган туганлык атамалары***ннан керәшен татарларында бийем, бийата, бийага, ак бийем, печкәчә, җанагай, кайнигәч, кайнага һ. б. сүзләр кулланыла.

Ир ягыннан туганлыкны белдерү өчен, керәшен сөйләшләрендә күбесенчә би/бий сүзе белән ясалган атамалар киң таралыш алган. Мәсәлән, бийата/бийатай/бийатый – ирнең әтисе, бийем / бийанам – ирнең әнисе, бийага / бийагый / бийагай – ирнең абыйсы һәм ак бийем – ирнең апасы. Килен аларга башка сүзләр белән дә мөрәҗәгать итә алган. Мәсәлән, төрле җирлекләрдә килennнең бийатасына – әтей, әтеки; бийанасына – әней, әнеки, инәкәй; ак бийеменә ак түти яки ак тәтә дип эндәшү дә күзәтелә.

Ирнең кече кардәшләрен белдергәндә генә, би / бий тамыры урын алмый. Ирнең энесен атау өчен, гарәп чыгышлы җан һәм төрки агай сүзләреннән ясалган җанагай (чистай керәшеннәре сөйләшендә йанагай варианты да бар [Баязитова, Хайбуллина, б. 171]), ә ирнең сеңлесен печкәчә / печкәчәм сүзләре белән белдерү хас. Җанагай сүзе урта диалектның күпчелек сөйләшләрендә кулланыла, керәшен сөйләшләреннән тыш, минзәлә, нократ сөйләшләрендә дә актив. Казан арты, чистай сөйләшләрендә печкә сүзе, бием белән бергә, кайнана мәгънәсендә дә урын алган. Бу борынгы сүз нократ татарлары сөйләшендә бечий – туган, кардәш тиешле кеше; башка төрки телләрдән чуваш телендә пичче – абый, өлкән ир туган; хакас телендә пиже – кыз туган; фин-угыр телләреннән удмурт телендә бече, бечей, беска – өлкән ир туганны белдерә [Баязитова, 1997, б. 92]. Татар этимологы Рифкать Әхмәтьянов печкә сүзенең килеп чыгышы ачык түгел дип күрсәтә [Әхмәтьянов, II т., б. 109]. Ирнең кече сеңлесенә иркәләп эндәшү формасы буларак, керәшеннәрдә ак печкә сүзе дә кулланылырга мөмкин. Тау ягы керәшен сөйләшендә исә шушы ук мәгънәдә сары кыз [Баязитова, 1997, б. 92–93] / саркыз атамасы, ә ирнең энесен белдерү өчен, сарул / сары ул сүзләре урын ала [Молькеевские кряшены, б. 138].

Керәшен сөйләшләрендә хатын ягыннан туганлыкны белдерә торган сүзләр, татар әдәби телендәге кебек үк, каен сүзе белән ясала: кайнигәч – хатынның апасы, кайнага – хатынның абыйсы, кайнеш / кайнеч – хатынның энесе. Тау ягы керәшеннәрендә кан’агач – хатынның апасы, каным – хатынның әтисе. Кайнигәч сүзендәге игәч тамыры күп телләрдә күзәтелә. Мисал өчен, монгол телендә эгч – өлкән кыз туган, якут телендә агас – әтисе ягыннан кыз туган, кумык телендә эгечи – әтисенең яки әнисенең апасы, балкар телендә эгеч – апа һ.б. Борынгы төрки телдә ека сүзе өлкән кыз туганны аңлаткан. Мишәр сөйләшләрендә игәч – шулай ук өлкән кыз туган.

Гомумән, татар телендә каен тамырыннан сүзләр ясау, нигездә, мишәр диалекты сөйләшләренә хас, ә би тамыры күбрәк урта диалект сөйләшләрендә күзәтелә. Туганлык атамаларын каен тамырыннан ясау башка төрки телләрдә дә (башкорт, казах, кыргыз, каракалпак, үзбәк, гагауз, азәрбайҗан, хакас, шор, тува, якут) киң таралган. Би тамыры ярдәмендә никах ягыннан булган туганлык терминнарын ясау чуваш теле (пайатам – кайната, пайанам – кайнана, пайохам – ирнең абыйсы) һәм башкорт теленең кайбер сөйләшләре өчен хас [Баязитова, 1997, б. 93].

Керәшен сөйләшләрендә өйләнешү нәтиҗәсендә барлыкка килгән кардәшлек атамаларының зур күпчелеге татар әдәби теле белән тәңгәл килә: ир, катын ‘хатын’, кийәү, килен, кода, кодагый/кодагий, кодача, җизней, җиңгей һ. б. Ир кеше өчен хатынының әтисе һәм әнисе дә, әдәби телдәге кебек үк, бабай һәм әби сүзләре белән белдерелә.

Күренгәнчә, керәшеннәрдәге туганлык атамалары күп һәм төрле. Алар арасында төрки телләрнең күбесе өчен уртак булганнары да, хәзерге татар әдәби теле белән тәңгәл килгәннәре дә, урта диалект һәм мишәр сөйләшләре белән охшашлык күзәтелгәннәре дә бар.

**Кием-салым һәм бизәнү әйберләре атамалары**

XX гасырга кадәр керәшеннәр киемнәрне үзләре сугып, тегеп һәм чигеп кигәннәр. Ләкин хәзерге вакытта аларның киеме татар халкының башка төркемнәреннән аерылмый. Элеккеге кием һәм бизәнү әйберләре исә буыннан буынга тапшырылып килә. Керәшен фольклор ансамбльләренең кайберләре шул иске киемнәрне кулланса, күбесе хәзерге вакытта үз якларында элек кулланылган үзенчәлекле кием үрнәкләре нигезендә тектерелгән сәхнә күлмәкләреннән чыгыш ясый.

Кием-салымнары, тәңкәле бизәнү әйберләренең формасы ягыннан керәшен киемнәре Идел буендагы күрше халыклар – удмуртлар һәм чувашлар киеменә охшаш, ләкин ул киемнәрнең атамалары күбесенчә – борынгыдан килгән төрки-татар сүзләре.

Керәшеннәрдәге шактый күп кием атамалары татар теле һәм диалектлары белән тәңгәл килә. Мәсәлән, күлмәк, ыштан, алҗапкыч ‘алъяпкыч’, җаулык ‘яулык’, шәл, калпак ‘калфак’, изү, чигәчә, беләзек, чулпы, сырга ‘алка’, җөзәк / йөзек, камзул, җилән, чикмән, тун, толып, бүрек, чарык / чәрик / чәрек ‘башмак, күн аяк киеме’ һ.б. Күренгәнчә, аларның күпчелеге гомум төрки сүзләрне тәшкил итә, бары шәл [Әхмәтьянов, II т., б. 483] һәм калпак [Әхмәтьянов, I т., б. 353] – фарсы сүзләре, камзул – рус теле аша алман теленнән кергән сүз [Әхмәтьянов, I т., б. 356], чулпы – Р. Әхмәтьяновча, иске монгол теленнән иске уйгыр теле аша кабул ителгән, ә С. Малов фикеренчә, кытай теленнән кергән сүз [Әхмәтьянов, II т., б. 454] дип санала.

Керәшеннәрдә әлеге киемнәрнең үзенчәлекле төрләре булырга һәм атамаларында үзгәрешләр дә күзәтелергә мөмкин. Мисал өчен, ***күлмәк***нең керәшеннәрдә түбәндәге төрләре аерыла: алача күлмәк (төрле төсләр белән бизәкләп сугылган киндердән тегелгән күлмәк, алачаның да гаять күп төрләре булган: вак шакмаклы, кызыл бишле, сары бишле, буй бишле, зур шакмаклы, шакмак эчендә кечерәк шакмаклы, оялап, сөрмәләп сугылган, сәрпинкә [Мөхәмәдова, б. 13] – буй-буй яки шакмаклы юка киҗе-мамык тукымадан тегелгән, грек сүзе [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, б. 464] һ. б.), тоташ буйлы күлмәк, таккан итәкле күлмәк, өске итәкле күлмәк [Мөхәмәдова, б. 39] һ. б., моннан тыш, тикшеренүчеләр күрсәткәнчә, казан арты һәм түбән кама керәшеннәрендә – калталы күлмәк (киң бала итәкле күлмәк) [Татар халык сөйләшләре: Беренче китап, б. 106, 123], [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, б. 383], чистай керәшеннәрендә – басма күлмәк (фабрика тукымасыннан тегелгән күлмәк), кырын итәкле күлмәк (ике яктан озынрак итәкле итеп тегелгән күлмәк), кәбенгә кергән күлмәк (1. чиркәүдә никахлашкан чакта киелгән күлмәк. 2. хәзерге туй күлмәге), бала итәкле яки бәбәй итәкле күлмәк [Баязитова, Хайбуллина, б. 179, 180], тау ягы керәшеннәрендә – ике итәкле күлмәк [Молькеевские кряшены, б. 66], минчәт (< рус венчать ‘чиркәүдә никах уку’) күлмәге [Баязитова, 1997, б. 101] һ. б. Керәшеннәр XX гасыр уртасына кадәр җитен яки киндердән өйдә үзләре тукыган тукымадан күлмәк, ыштан, алъяпкыч һәм сөлге-тастымаллар теккәннәр. Күлмәкләрне борынгы туника формасындагы өлгене саклап, тоташ иңле итеп, җиң төпләренә кештәкләр куеп эшләгәннәр. Белгечләр фикеренчә, керәшен киеме традицияләре күп гасырлар дәвамында тотрыклы хәлдә сакланып калган [Мөхәмәдова, б. 12].

***Алҗапкыч***, кайбер сөйләшләрдә – ***алчуперәк*** шулай ук керәшеннәрнең бик борынгы һәм яратып киелә торган үзенчәлекле

киеме булган. Аны көндәлек һәм бәйрәм киеме буларак кулланганнар. Алҗапкычны күбрәк өйдә эре шакмаклап, алмалап, сөрмәләп, чуптарлап, ягъни бизәкләп сугылган тукымадан күкрәкчәле итеп теккәннәр.

Шулай да керәшен татарларындагы иң үзенчәлекле кием төрләрен баш киемнәре һәм бизәнү әйберләре тәшкил итә. Кызлар баш киеме хатыннарныкыннан аерылган. Кызлар, буй җитә башлагач, озын ***калпак***лар кигәннәр, маңгайларына ***ука-чачак*** (укадан, ягъни елтыравыклы җепләр катнаштырып һәм чачаклап эшләнгән бизәнү әйбере) бәйләгәннәр. Ак яки төрле төстәге җептән бәйләп эшләнгән озын калфаклар әүвәлгерәк чорларда, хәтфә калфаклар таралганчы, барлык татар кызлары өчен дә хас булган. Ләкин керәшен кызларында бу төр кызлар калпагы аеруча тотрыклы сакланган. Мондый озын калпакны башка кигәндә, аның кырыен ике кат бөкләгәннәр һәм өстән маңгайга ука-чачак бәйләгәннәр. Калпакның чуклы очы аркага яки иңгә төшеп торган. Ә кара хәтфәдән яки башка төрле кара төстәге фабрика тукымасыннан чигеп эшләнгән озын калпаклар бигрәк тә мишә буе керәшен татарлары арасында сакланып калган. Аларның күбесе тамбур ысулы кулланып чигелгән, орнаментларында төрки халыкларга хас кояш, чәчәк мотивлары очрый. Кызлар толымнарына, чәч төбенә беркетеп, ике яки өч рәт вак көмеш тәңкәләр белән бизәлгән ***чәчкабы*** бәйләргә яратканнар, чәчкабының өске очына ***чулпы***лар беркетелә торган булган.

Тау ягы яки мәлки төркеме керәшен кызларының баш киемнәре арасында төрки халыкларга хас тәңкәле ***такыйа*** сакланып калган. Гарәп теленнән кергән әлеге сүзнең хәзерге татар әдәби телендәге һәм диалектлардагы мәгънәләре бик нык аерыла. Әдәби телдә такыя сүзе 1) елтыркалар, тәңкәләр, сәйләннәр һ. б. белән бизәлгән сай цилиндр сыман хатын-кыз баш киеме; 2) чәчләрне яшерү өчен, ашчылар, пешекчеләр кия торган биек ак кәпәч; 3) чәчәкләрдән үрелеп, вакытлыча башка киелә торган бөҗра [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, б. 510] буларак билгеләнә, сөйләмдә күбрәк өченче мәгънәсе кулланыла. Татар теленең төрле сөйләшләрендә исә такийа / такийә / такйа сүзләренең ирләр түбәтәе; бүрек; олырак яшьтәге хатын-кызларның яулык өстеннән кия торган бәрхет баш киеме [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, б. 602, 292] дигән мәгънәләре дә урын ала. Мәлки керәшен кызларының такыйасы бөтенләй башка төрле баш киемен тәшкил итә. Ул ярым түгәрәк формада, иң өскә агач яки аккургаш кебек каты материалдан 2–3 см биеклектәге оч ясалып, асты колакчынлы итеп эшләнгән, өске өлеше – төрле төстәге сәйләннәр, ә аскы ягы вак көмеш тәңкәләр белән бизәлгән баш киеме [Мөхәмәдова, б. 42]. «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»ндә исә ул «тау ягы керәшеннәрендә яшь киленнең мәрҗәннәр белән чигелгән конус формасындагы баш киеме» [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, б. 602] дип бирелә. Шулай да такыя кызлар баш киеме булып санала. Элекке вакытларда ул татар халкының барлык төркемнәрендә дә булган, шулай ук башка төрки халыкларда һәм фин-угыр халыкларында кызлар баш киеме буларак билгеле [Воробьев, б. 41]. Чувашларда тухья – кызлар баш киеме, такыя, тухъя – башкортларда һәм Идел буеның фин-угыр халыкларында: мари, удмурт, бисермәннәрдә, ягъни төрки халыклар белән элек-электән аралашып яшәгән күршеләрдә дә кызлар кия торган баш киеме такыя дип аталган [Баязитова, 1997, б. 94]. Мәлки керәшен кызларының такыйасы чувашларның тухьясы белән бик охшаш.

Кияүгә чыккач, кызлар баш киемен хатыннарныкына алыштырганнар. Керәшеннәрнең күпчелегендә аңа мәләнчек, чигәчә, сүрәкә һәм түгәрәк җаулык тәшкил иткән, кайбер аерым төркемнәрендә исә чукул, тастар һәм тастар җаулык кулланылган.

***Мәләнчек*** (аның шулай ук ***мәләчлек / мәрәчлек / бәләчлек*** вариантлары да бар) – башка баш киемнәре астына киеп калдырыла торган чәч каплавычы, башны кысып бәйләп куела торган, чепчик сыман баш киеме. Бу сүзнең килеп чыгышы төгәл билгеле түгел. Р. Әхмәтьянов аны фарсы теленнән кергән булырга тиеш дип күрсәтә, шулай ук рус телендәге волосник (волос – чәч) сүзенә бәйләүчеләр дә бар [Әхмәтьянов, II т., б. 28]. Хатыннар, чәч толымнарын башларына урап куеп, тукымадан эшләнгән һәм чәчләрен тулысынча каплап торган мәләнчек кигәннәр. Мәләнчекнең маңгай турысына туры килә торган җиренә, баш киеменең алгы ягы биек булып торсын өчен, каты кәгазь яки юка такта кисәге – мәләнчек калагы беркетелгән була. Аның формасы төрле төркемнәрдә аерыла: Казан артының Мишә буе төркемендә – дүртпочмак рәвешендә, Чистай керәшеннәрендә – квадрат формасында, Көнчыгыш Кама

аръягы төркемендә – озынча, ләкин өсте бераз түгәрәкләнеп торган, ә Алабуга керәшеннәрендә дуга формасында булган.

Мәләнчек өстеннән башта чигәчә, аннары сүрәкә киелгән. ***Чигәчә*** (чигә+чә) – чигә турысына тәңкәләр тезелгән баш киеме. Казан арты керәшеннәрендә бу сүз урынына ***җилкәлек*** (җилкә+лек) атамасы кулланылган [Баязитова, 1997, б. 96]. Аның шулай ук ***чигәлек*** (чигә+лек), ***җаңакса*** атамалары да билгеле. Әлеге бизәнү әйберенең астары дүрт почмаклы яки түгәрәкләнеп килгән кырыйлы булган [Мөхәмәдова, б. 20]. ***Сүрәкә*** баш киеме өч өлештән торган: маңгайча, «канатлары» һәм «койрыгы». Маңгайчасы һәм канатлары укалы, ә аркага төшеп торган койрыгы кызыл яки зәңгәр тукымадан булып, тасмалар яки төрле төстәге тукымалар белән бизәлгән, кайбер очракта аскы очына тар итәк тә тотылган була. Сүрәкә маңгайчасының формасы мәләнчек калагының формасына туры килергә тиеш булган, чөнки сүрәкәне башка бәйләгәндә, аның маңгай өлеше мәләнчек калагына кигезелгән, аннары канатларының очларына бәйләнгән тасмалар белән башның артына беркетелеп куелган [Мөхәмәдова, б. 16].

Керәшеннәрдәге сүрәкә формасында булган баш киеме русларда (сорока ‘саескан’) һәм мариларда (сорака) бар. Бу баш киеме һәм аны белдерә торган сүз төрки халыкларда башка бәйли торган урама, яулык мәгънәсенә туры килә торган борынгы сүзләр: сарук, саруг, сарик, сарги формаларыннан үзгәртелеп, рус һәм фин-угыр телләренә кереп киткән дигән фикерләр дә бар [Баязитова, 1997, б. 96]. Д. Рамазанова да аны башта төрки телләрдән рус теленә кергән, аннары кире төрки телләргә әйләнеп кайткан сүз дип саный. Борынгы төрки телдәге сару –урау мәгънәсенә кайтып кала. В. Радлов сүзлегендә сүрәкә сүзенең ике мәгънәсен күрсәтелә: 1) балык тоту өчен сөкә, ятьмә; 2) мәләчлек өстеннән киелә торган хатын-кыз баш киеме [Рамазанова, 2002, б. 155]. Ф. Баязитова һәм Г. Хәйбуллина сүрәкәне татар телендәге сару ука ‘сары ука’дан килеп чыккан булырга мөмкин дип билгелиләр [Баязитова, Хайбуллина, б. 187]. Р. Әхмәтьянов бу сүзнең килеп чыгышы рус телендәге сорокадан булу ихтималлыгын күрсәтә [Әхмәтьянов, II т., б. 185], Р. Мөхәмәдова исә сүр (бу тамырдан мендәр сүрүе сүзтезмәсе бар, ә сүрәкә – мәләнчек сүрүе мәгънәсе) һәм һинд-европа телләрендә «ана», «имезүче хатын» мәгънәсендә кулланылган акка терминына барып тоташа торган әкәй сүзләре кушылудан килеп чыккан дип бәяли, шул ук вакытта сүр сүзен фарсыдан кергән сор ‘баш’ сүзе белән бәйләсәң дә, баш яулыгына туры килә, мари телендә мөгез мәгънәсендә кулланылган щур, чур формалары белән бәйләүнең дә нигезе бар кебек дип күрсәтә, чөнки, аның сүзләренчә, сүрәкә биек маңгайчалы, ягъни «мөгезле» баш киемен тәшкил итә [Мөхәмәдова, б. 17-18]. Аңлашылганча, әлеге баш киеме атамасының килеп чыгышы хакында фәндә гаять төрле фикерләр хөкем сөрә.

Алабуга керәшеннәрендә сүрәкәгә охшаш, ләкин хатыннарның көндәлек баш киемен тәшкил иткән ***чукул / чукол*** баш киеме кулланылган. Аның аркага төшеп торган өлеше сүрәкәнең койрыгы зурлыгында булып, өске, маңгайга туры килгән өлешенә төрле төстәге тасмалардан маңгайча тотылган була. Бәйрәм вакытларында маңгайча өстеннән ***маңгай тәңкәсе*** яки ***маңгай укасы*** – маңгай турысына тәңкәләр тезелгән яки ука тотылган баш киеме бәйләгәннәр [Мөхәмәдова, б. 17, 20]. Ф. Баязитовада һәм «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»ндә исә чукул сүзе башка мәгънәдәрәк аңлатыла: «сүрәкә, маңгай ука һәм маңгай тәңкәнең арткы өлешенә беркетелгән материя, алабуга керәшеннәрендә шулай атала. Ул арканы каплап тора, очына, гадәттә, челтәр тотылган була. Казан арты, чистай керәшеннәрендә шул ук мәгънәдә сүрәкә канаты дигән сүз кулланыла» [Баязитова, 1997, б. 96] яки «казан арты һәм түбән кама керәшеннәрендә сүрәкә яки мәләнчекнең арткы өлешенә беркетелгән яулык сыман ефәк тукыма кисәге» [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, б. 761]. Нагайбәкләр киемендә дә чукул атамасы чукул, ***чакул*** һәм чукол вариантларында бөркәнчек буларак аңлатыла, сүрәкә кебек баш киеме, ләкин аның чигәне каплый торган «канатлары» булмаган дип күрсәтелә [Нагайбаки, б. 57]. Күп чыганакларда аңлатмалар урын алса да, кызганыч, чукул / чукол сүзенең килеп чыгышы хакында бернинди фикер дә табылмады.

Яшь киленнәргә мәләнчек, чигәчә һәм сүрәкә өстеннән ***түгәрәк җаулык*** бөркәндерә торган булганнар. Элекке вакытта аны киленнәр бәйрәм көннәрендә якынча бер ел дәвамында, төгәлрәге, бала туганчы ябынганнар. Яулык түгәрәк дип аталса да, формасы белән дүрт почмаклы ак киндерне тәшкил иткән. Аның читләренә кызгылт җептән үрелгән чуклар, ә маңгайга туры килә торган

җиренә өч рәт тәңкә тагылган була. Түгәрәк җаулыкның урта өлешенә һәм почмакларына катлаулы, дөресрәге, ике ысул кулланып чигелгән ике катлы нәкыш төшерелгән. Яулыкның аскы ягындагы бизәге, нигездә, кызгылт ефәк җепләр белән шома чигү техникасында эшләнгән. Бу матур бизәкне яулыкның астары каплап торган һәм аны кеше күрмәгән. Ә тышкы ягында кара төстәге калын ефәк җеп белән х, + яки аларның вариантлары формасында элмәкләп чигү ысулында башкарылган бизәкләр калкып торган. Бүгенге көн күзлегеннән караганда, әлеге шактый сәер чигү үрнәкләрендә төрки әби-бабайларның мәҗүсилек чорындагы дөньяга карашы чагыла булса кирәк. Борынгы төркиләр җирне ике катлы дүртпочмак формасында дип уйлаганнар. Нәкышнең ике яклы (ике катлы) булуы нәкъ менә шуның белән бәйле диярга мөмкин. Яулыкның өске ягындагы бизәкләр – символлар, ягъни алар магик сәнгать үрнәкләре булып торалар. Керәшен яулыкларындагы бу бизәкләр өстәмә махсус тикшеренүләр таләп итә [Мөхәмәдова, б. 18].

Керәшеннәрдә олырак хатын-кызлар бәйли торган баш киеме ***ак җаулык*** дип атап йөртелгән. Яулык дип аталса да, ул сөлге формасында һәм ике очы да алдарак сурәтләп үтелгән борынгы ысулда чигелгән булган. Аны хатыннар буйга өчкә бөкләп, сүрәкә өстеннән бәйләгәннәр, дөресрәге, чалма рәвешендә ураганнар. Бу вакытта аның чигешле очлары чигә турысына китереп беркетелгән. Этнограф Й. Мөхәмматшин хезмәтләреннән күренгәнчә, керәшеннәрдәге ак җаулык формасы һәм чигү үрнәкләре ягыннан чувашлардагы сурпан тутри һәм пус тутри дигән баш киеменә бик охшаш [Мухаметшин, б. 121]. Нагайбәкләр киеме турында язганда, В. Суслова аларда ак җаулыкны хатыннарның кияүгә чыкканнан соң 10–15 ел вакыт узгач ябулары һәм картайганчы сүрәкә өстеннән бәйләүләре хакында хәбәр итә [Нагайбаки, б. 58]. Чистай керәшеннәрендә исә шуңа охшаш баш киеме ***катыннар җаулыгы*** дип аталган, аның төсе зәңгәр, озынлыгы кыскарак һәм чуклы яки маңгайга туры килә торган җиренә ука тотылган булган [Мөхәмәдова, б. 19], [Баязитова, 1997, б. 97]. Шул ук вакытта чистай керәшеннәрендә дә катыннар җаулыгысы ак төстә булган дигән мәгълүмат та бар.

Керәшен хатын-кызларында шулай ук ***дарай җаулык*** дигән баш киеме дә билгеле. Ул күбрәк кызыл төстәге ефәк тукымадан эшләнгән һәм гадәттә чәчәкле булган. Дарай сүзе башка төрки халыкларда да ефәк мәгънәсен белдерә: ногай телендә даьрйе – ефәк шәл, кумык телендә дарай – тафта, дарай челек – тафта күлмәк [Баязитова, 1997, б. 97]. Р. Әхмәтьянов дарай сүзен «кыйммәтле көнчыгыш тукымасы» дип билгеләп, «калын ефәк тукыма, комач» мәгънәсендә бик күп телләрдә кулланылуын санап үтә, килеп чыгышын исә фарсы, төрек телләре аша Дарий патша исеменнән дип күрсәтә [Әхмәтьянов, I т., б. 240].

Тау ягы яки мәлки хатыннарында исә әлеге баш киемнәре булмаган. Бу яктагы кызлар такыя кисә, хатыннарга тастар, тастар җаулыгы һәм кашпау хас була. ***Тастар*** сүзе фарсы теленнән кабул ителгән, анда ул чалма, яулык мәгънәсен белдергән [Әхмәтьянов, II т., б. 222]. Тастар да, ак җаулык кебек үк, сөлге формасында өйдә тукылган ак киндердән эшләнгән, ләкин ул озынрак булган һәм очлары төрле төстәге җепләр белән туку ысулы кулланып бизәлгән, астына тамбур чигешле комач һәм очына ак челтәр тотылган. Тастарны башка бәйләгәндә, аның очлары, ияк астыннан яңакларны һәм муенны каплап үтеп, аркага берсе өстенә икенчесе салындырып куелган. Тастар башта нык торсын өчен, аның өстеннән кыска сөлге формасындагы ***тастар җаулыгы*** бәйләгәннәр. Аның да очлары туку ысулында бизәлгән. Тастар баш киеме аналоглары кайбер мишәр һәм чуваш төркеме хатыннарында да булган. Гомумән, сөлге формасындагы баш яулыклары фин-угырларда да, борынгы чорларда славян төркеменә кергән халыклар киемендә дә очрый. Этнографлар фикеренчә, мондый баш яулыклары, беренче чиратта, Урта Азиядә яшәүче төрки халыклардагы хатыннар киеменә хас. Урта Идел төбәгендә дә алар шактый иртә таралган булырга тиеш. Озак еллар дәвамында һәр җирлектә аларның төрле вариантлары барлыкка килә [Мөхәмәдова, б. 19, 26].

Бәйрәм көннәрендә мәлки хатыннары башларына ***кашпау*** кигәннәр. Бу сүзнең ***кашбау / кашмау*** әйтелеш вариантлары да бар. Төрки сүз булып санала, каш һәм бау (баг) сүзләреннән ясалган, ягъни каш өстенә кадәр төшеп тора торган баш киеме. Шулай ук төрле фонетик вариантларын төрлечә ясалган дип аңлату да күзәтелә. Мәсәлән, кашмау сүзендәге маw өлеше – кытай телендәге «хатын-кыз бүреге», ә кашпау сүзендәге паw сүзе фарсы телендәге пак ~ паг «каш (маңгай) киеме»ннән

алынган дип бирү дә бар [Әхмәтьянов, I т., б. 386]. Кашпау киселгән конус формасында тегелгән, аскы өлешенә – эрерәк, ә өскә таба ваграк тәңкәләр һәм сәйләннәр тезелгән булган. Мондый баш киеме элек казан татарларында киң таралган була. Шулай ук мишәр татарларының ләмбрә (кашпау) һәм темников (кашбау) төркемнәрендә, башкортларда (кашмау), чувашларда (хушпу) һәм бисермәннәрдә (кашпу) дә бар. Димәк, кашпау кайчандыр Идел буе төрки халыкларында киң таралган баш киеме булган дигән нәтиҗә ясарга нигез бар [Баязитова, 1997, б. 95].

Керәшен хатын-кызларының бизәнү әйберләре дә күп очракта тәңкәләр, сәйләннәр, мәрҗән һәм асылташлар тегеп, ука тотып эшләнгән була. Алдарак телгә алынган чигәчә (җилкәлек, җаңакса), маңгай тәңкәсе, маңгай укасыннан тыш, керәшеннәрдә муенса (муенҗака, тамакса), түшлек (изү, сакал, дәwәт), кәсилә / кәситә, мыйтумар / муйтомар / бут’умар / буйтымар / буйдымар, сырга, чулпы, чәчкап, беләзек, балдак, җөзәк / йөзек һ.б. бизәнү әйберләре дә урын алган.

Муен-күкрәк бизәү әйберләрен хатын-кызлар үзләре көмеш тәңкәләрне каты астарга тагып ясый торган булганнар. Астарның формасына карап, әлеге бизәнү әйберләрен өч төргә бүлергә мөмкин: муенса, түшлек һәм хәситә формасындагылар.

***Муенса*** (чистай керәшеннәрендә – ***бун’са***, нагайбәкләрдә – ***муйса***) – аскы өлеше түгәрәкләнеп торган зур булмаган астарга тәңкәләр тезеп эшләнгән һәм арттан бәйләп куела торган муен бизәгече. Аның шулай ук ***тамакса*** (тамак+са) һәм ***муенҗака*** (муен+яка) атамалары да кулланылган. Соңгысын кыскартып, ***мун’җака*** дип тә атаганнар. Муенсаның өске кырыена (муенга ятып тора торган өлешенә) – кызыл мәрҗән, ә аскы читенә җиде эре (бер сумлык) тәңкә тегелгән. Кайбер төркемнәрдә мәрҗән белән эре тәңкәләр арасына өстәмә 2–3 рәт ваграк (50 һәм 20 тиенлек) тәңкәләр тагылган вариантлар да очрый. Муенса – керәшен хатын-кызлары арасында киң таралган һәм көндәлек кием комплексына хас бизәнү әйбере. Көнчыгыш кама аръягы керәшен хатыннарында чылбырлы яки чылбыр җибәрелгән муенсалар да кулланылган. Сәнгать белгечләре фикеренчә, бу муенса чылбырлары белән Казан мөселман хатын-кызларының затлы яка чылбырлары арасында типологик охшашлык бар [Мөхәмәдова, б. 21]. Нагайбәкләрдә яка чылбыры кебек зур булмаган бизәнү әйбере муйса дип аталган, шулай ук муенса атамасы да бирелә [Нагайбаки, б. 59, 61].

Хатыннарның бөтен түшләрен каплап торган, кайвакыт хәтта билдән дә түбән озынлыктагы ярымтүгәрәк яки дүртпочмаклы астарга укалар тотып, тәңкәләр тезеп ясалган зур күкрәкчәләр керәшен төркемнәрендә төрлечә аталганнар. Казан арты керәшен-нәрендә аны ***түшлек*** (түш+лек) диләр. Биредә, тәңкәләрдән генә торган түшлекләр белән беррәттән, ука һәм асылташлар белән бизәлгән, мөселман татар хатыннарының изүен хәтерләткән түшлекләр дә очрый. Көнчыгыш кама аръягы төбәгендә зур астарлы, тәңкәле күкрәк бизәгече ***изү*** дип аталган. Аны чылбырлы муенса белән бергә бәйләгәннәр. Изү һәм түш борынгы төрки сүзләр булып санала [Әхмәтьянов, I т., б. 295], [Әхмәтьянов, II т., б. 330]. Алабуга керәшеннәрендә зур астарга тәңкәләр тезелгән күкрәк бизәгечен ***дәwәт*** дигәннәр. Биредә дә муенса өстеннән чылбыр җибәрү традициясе булган [Мөхәмәдова, б. 21]. Дәwәт сүзе хәзерге татар телендә бөтенләй кулланылмый, ләкин күп диалектларда урын ала. Фарсы яки гарәп теленнән кергән дип карала торган әлеге сүзнең ике мәгънәсе бар: «кара савыты» мәгънәсендә дәwәт күп төрки телләрдә (мәсәлән, ногай, казах, каракалпак) очрый, ә «иңгә кыеклап куелган киң тасма» мәгънәсендә күрше телләргә дә (мәсәлән, чуваш, мари) кергән. Бу беренче карашка бер-берсеннән ерак торган мәгънәләрнең бер чыганактан килгәнлеге шуның белән аңлатыла: борынгы бетекчеләр үзләренең кара савытларын иңгә кыеклап бәйләнгән киң тасмага беркетеп асып йөрткәннәр [Әхмәтьянов, I т., б. 295], Әхмәтьянов, II т., б. 241]. «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»ндә түбән кама керәшеннәре тәңкәле түшлекне ***сакал*** дип атаганнар дип бирелә, ә икенче урында исә түбән кама һәм чистай керәшеннәрендә дәwәт сүзе кулланылуы хакында әйтелә [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, б. 556, 164]. Ф. Баязитова Алабуга районы керәшеннәрендә һәм Казан арты төбәгендәге берничә авылда сакал тәңкәле бизәнү әйбере буларак билгеле дип күрсәтә. Шундый ук күкрәкчәләр башкортларда да сакал дип аталган [Баязитова, 1997, б. 99]. Бик күп телләрдә, шул исәптән төрки телләрдә дә төрле фонетик вариантларда кулланылган сакал сүзе борынгы монгол телендәге «күп катлы муенса, бергә киелгән

күп муенса» мәгънәсен белдергән сүздән алынган дип карала [Әхмәтьянов, II т., б. 133]. Күренгәнчә, тәңкәле зур күкрәкчәләрнең исемнәре күп төрле, галимнәр тарафыннан да алар төрлечә бирелә.

Борынгы чорга караган күкрәк бизәгечләренең тагын берсе – хәситә. Керәшеннәр арасында аның шулай ук бик күп төрле атамалары булган, ләкин алар нигездә ике сүзгә кайтып кала: ***кәсилә / кәситә, мыйтумар / муйтомар / бут'умар / буйтымар / буйдымар***. Әлеге бизәгеч өч-дүрт рәт тәңкә тезеп ясалган, бер иңбашыннан икенче як култык астына киелә торган укалы киң тасманы тәшкил иткән. Кәсилә/кәситә вариантлары татар әдәби телендә хәситә буларак билгеле сүздән үзгәртеп ясалган һәм күбрәк казан арты керәшеннәре сөйләше өчен хас. Татар әдәби телендә хәситә – күлмәк өстеннән киелә торган, алтын-көмеш акчалар һәм ука асылташлар белән бизәлгән күкрәкчә [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, б. 640]. Р. Әхмәтьянов хәситәне гарәп телендәге касыйдә «махсус шигъри формадагы мактау җыры» сүзеннән килеп чыккан дип карый, аның аңлатуы буенча, «борынгы гадәтчә, кызлар үзләренә багышланган мактау шигырен бөти итеп йөрткәннәр» [Әхмәтьянов, II т., б. 388]. Мыйтумар/бут'умар сүзләре алабуга керәшеннәрендә кулланыла, ә Мамадыш районы Керәшен Пакшин авылында буйдымар рәвешендә сакланып калган. Хәситәне бут'мар, пут'мар, пут'емар, пут'ымар дип атау мишәр сөйләшләренә дә хас. Бу исә аның бик борынгылыгын һәм кайчандыр киң кулланылышта булуын дәлилли. Башка төрки теллардән үзбәк телендә буйин тумор – муенга тага торган бизәнү әйбере, ногай телендә мой-тумар, мойын-тымар – талисман. Көньяк удмурт һәм бисермәннәрдә дә бут'мар сүзе, татар сөйләшләрендәге кебек үк, күкрәккә киелә торган бизәнү әйберен белдерә [Баязитова, 1997, б. 98].

Кулны бизәү өчен кулланылган бизәнү әйберләреннән керәшен хатын-кызлары да беләзекләр һәм балдак-йөзекләр кияргә яратканнар. Аларда тоташ, чокып бизәкләр төшерелгән яссы ***беләзек***ләр киң таралган була. Аларның аскы кырыена өч вак тәңкә тагылганнары да очрый [Мөхәмәдова, б. 21]. Андый беләзекне, мәсәлән, Чистай керәшеннәре ***челтермәкле беләзек*** дип атаган [Баязитова, Хайбуллина, б. 189], ә нагайбәкләрдә ***чылбырлы беләзек*** дип йөртелгән. Аларда шулай ук гел тәңкәләрдән генә ясалган ***тәңкәле беләзекләр*** дә булган [Нагайбаки, б. 59]. Беләзек сүзе борынгы төрки сүз булып санала [Баязитова, Хайбуллина, б. 189].

Керәшеннәр зур ахак (сердолик) кашлы ***җөзәк / йөзек***ләрне һәм шома, кашсыз ***балдак***ларны яратып кигәннәр. Хатын-кыз балдакларының аскы кырыена ике вак тәңкә беркетү гадәте дә хас булган. Гомумән, керәшеннәрдә балдак чиркәү никахының атрибуты буларак таралган булса кирәк. Асылташлар куеп эшләнгән йөзекләр исә бизәнү әйберләре арасында сирәк очрый.

Шулай ук керәшен хатын-кызларында ювелир осталыгы таләп ителгән олы сырга, кызлар чәчтезмәсе – чәчкабы һәм ахак кашлы зур чулпылар аерым бер урын алып тора. Катлаулы ысуллар белән зиннәтләп эшләнгән әлеге бизәнү әйберләре татар хатын-кызларының борынгы кием стиленә хас булган. Мөселман татар хатын-кызларының яңа, милли кием стилендә аларның кечерәк, җиңелрәк вариантлары таралыш ала. Керәшеннәрдә исә татар хатын-кызларына хас челтәрле олы ***сырга***лар күбрәк кызларның баш киеме комплексында очрый. Кызлар аларны колакларына кигезмичә, озын тасмага (аны сырга бавы дип атаганнар) беркетеп, колаклары артыннан әйләндереп, яңакларына төшереп элгәннәр [Мөхәмәдова, б. 21–22]. Нагайбәкләрдә зур булмаган сыргалардан ***дуганак*** (дуга формасында) һәм ***йерәкле сырга*** (йөрәк формасында) атамалары китерелә, ә зурысы бары сырга дип кенә аталганлыгы аңлашыла [Нагайбаки, б. 58]. Сырга керәшен хатын-кызларының бизәнү әйберләре арасында киң кулланылышта булган. Аны ***олы сырга***, ***кечти*** 'кечкенә' ***сырга*** дип тә аерып йөрткәннәр. Сырга – борынгы төрки сүз, башка төрки халыклардан башкорт телендә һырга, алтай телләрендә сырга, ызырга, якут телендә ытырга вариантларында кулланыла [Баязитова, 1997, б. 100].

Зур ***чулпы***лар да татар хатын-кызларының киң таралган бизәнү әйберләре булып саналалар. Аларның гадиләре дә, буынлылары да, көянтәлеләре дә бар. Ләкин керәшен хатыннары, чукынганнан соң, чәч толымнарын аркага салындырып йөрмиләр, баш әйләнәсенә урап, мәләнчек кияләр. Шуңа күрә аларга чулпыларның кирәге калмый кебек. Ләкин борынгы зур ахак ташлы бу чулпылар югалмаганнар. Аларны кызлар кара төстәге тар,

каты астарга ике яки өч рәт вак тәңкә тезеп эшләнгән чәчкапларының аскы очына беркетеп куя торган булганнар. ***Чәчкабы / чәчкап*** (чәч+кап) чәч толымының төбенә бәйләнгән һәм толымнар өстенә төшеп торган [Мөхәмәдова, б. 20]. Чистай керәшеннәре төркемендә чәчкап сүзе урынына ***чәчтәңкә*** (чәч+тәңкә) яки ***көмеш тәңкә*** (*чәч ти очларыңда көмеш тәңкә*) атамалары кулланылган [Баязитова, Хайбуллина, б. 190–191]. Нагайбәкләрдә исә тикшеренүчеләр тарафыннан ***чәч бау*** атамасы күрсәтелә. Аларда XX гасыр башына ак калпаклар кулланылыштан чыга башлый, ләкин чәч бауны өчпочмаклап ияк астыннан бәйләнгән яулыклар белән дә кияләр. Шулай ук 3–5 ботак чәч бау дигән атама да урын ала, бу очракта чәч бау очына тукымадан 3–5 тар кисәк тегеп куела да аңа вак тәңкәләр тезелә [Нагайбаки, б. 56].

Керәшен татарлары киемнәре һәм аларның атамаларына күзәтү ясаганнан соң, көндәлек кием исемнәренең нигездә татар халкының башка төркемнәре белән тәңгәл килүен, күпчелегенең гомум төрки терминнар булуын (күлмәк, ыштан, алҗапкыч, җаулык, беләзек, сырга, чигәчә, чигәлек, җилкәлек, кашпау, җилән, чикмән, тун, толып, бүрек, чарык / чәрик / чәрек һ. б.), шулай ук араларында башка телләрдән кергән, мәсәлән, фарсы (тастар, шәл, калпак, дарай), гарәп (такыйа, кәсилә / кәситә), монгол (сакал), алман (камзул) алынмасы дип каралганнары да барлыгын, ә бер төркем сүзләрнең килеп чыгышы хакында төрле фикерләр күзәтелүен (мәләнчек, сүрәкә, чулпы, дәwәт һ. б.) яки, киресенчә, этимологиясе аңлатылмавын (чукул / чукол, мыйтумар / муйтомар / бут’умар / буйтымар / буйдымар) да күрдек. Бигрәк тә керәшен хатын-кызлары баш киемнәре гаять үзенчәлекле һәм төрле булулары белән аерылып тора. Керәшеннәрнең яшәү урыннарына бәйле рәвештә, аларның атамаларында һәм кулланылышында күп төрле вариантлар барлыкка килгән. Алар арасында бер үк сүзнең төрле фонетик вариантлары булуын (мисал өчен, мәләнчек / мәләчлек / мәрәчлек / бәләчлек, кашпау / кашбау / кашмау һ. б.) һәм бер үк киемнең төрле төркемнәрдә төрлечә аталуын (мәсәлән, муенса, бун’са, муйса, муенҗака, тамакса; түшлек, изү, дәwәт, сакал һ. б.) аерып билгеләргә мөмкин. Эчтәлеге атаманың туры мәгънәсенә яки хәзерге вакыттагы аңламына туры килмәгән терминнар да шактый күп күзәтелде, мәсәлән, түгәрәк җаулык, ак җаулык, сакал, изү, муенса, такыйа, калпак һ. б.

Татар халкының башка төркемнәреннән аерымланып, христиан динен кабул иткән күрше чуваш, удмурт, мари һ.б. халыклар белән якынаебрак яши башлаган керәшен киемнәрендә борынгы төрки-татар киеме үзенчәлекләре күп гасырлар дәвамында сакланып килгән, шул ук вакытта ул күрше халыкларның йогынтысын да кичергән [Ercan Alkaya, Zoya Kirillova, б. 155–178].

Йомгак ясап әйткәндә, керәшеннәр сөйләмендә борынгы элементлар сакланып калган. Керәшен сөйләшләре өчен генә хас булган лексик катлам аеруча әһәмиятле. Әлеге катламга туганлык атамалары, кием-салым һәм бизәнү әйберләре исемнәре, бәйрәм һәм йола атамалары һ. б. керә.

**Әдәбият**


*Әхмәтьянов Р. Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге, I том (А–Л). Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 543 б.

*Әхмәтьянов Р. Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге, II том (М–Я). Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 567 б.

*Мөхәмәдова Р. Г.* Керәшен татарлары киеме. Казан: Сүз, 2005. 159 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. Казан: Татар. китап нәшр., 2009. 839 б.

Татар халык сөйләшләре: Ике китапта: Беренче китап / Ф. С. Баязитова, Д. Б. Рамазанова, Т. Х. Хәйретдинова һ. б. Казан: Мәгариф, 2008. 463 б.

Татар халык сөйләшләре: Ике китапта: Икенче китап / Ф. С. Баязитова, Д. Б. Рамазанова, Т. Х. Хәйретдинова һ. б. Казан: Мәгариф, 2008. 495 б.

*Баязитова Ф. С.* Говоры татар-кряшен в сравнительном освещении. М.: Наука, 1986. 248 с.

*Баязитова Ф. С.* Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты. Казан: Матбугат йорты, 1997. 248 б.

*Баязитова Ф. С., Мухаметова Г. Ф.* Язык и культура: этнографические исследования по татарским говорам региона юго-восточного Закамья Татарстана (чистопольский, мензелинский, крещено-татарский говоры). Казань: Алма-Лит, 2008. 284 с.

*Баязитова Ф. С., Хайбуллина Г. Х.* Язык и культура: этнолингвистические и этноконфессиональные особенности татарских говоров Западного Закамья Татарстана. Казань, 2013. 400 с.

*Белицер В. Н.* Народная одежда удмуртов. Москва: изд-во Академии наук СССР, 1951.

*Воробьев Н.И.* Казанские татары. Казань: Таттосиздат, 1953. 383 с.

*Кириллова З. Н.* Древнетюркские слова и заимствования в говорах кряшен как отражение народной культуры в диалектной картине мира // Изучение региональной картины мира в поликультурном образовательном пространстве: теория и практика / Министерство образования и науки Республики Татарстан; Казанский федеральный университет; под общей ред. Л. А. Мардиевой, Т. Ю. Щуклиной, Л. А. Усмановой. Казань: РИЦ «ШКОЛА», 2017. С. 65–71.

*Кириллова З. Н.* Чувашские и древнетюркские слова в говорах крещеных татар // Языковые контакты народов Поволжья и Урала: сб. ст. XI Междунар. симпозиума (Чебоксары, 21–24 мая 2018 г.) / сост. и отв. ред. А.М. Иванова, Э.В. Фомин. Чебоксары: изд-во Чуваш. ун-та, 2018. С. 72–75.

*Малов С. Е.* Памятники древнетюркской письменности: тексты и исследования. М.-Л.: изд-во АН СССР, 1951. 451 с.

*Махмутова Л. Т.* Некоторые материалы по лексике мишарского диалекта татарского языка // Исследования по исторической диалектологии татарского языка. Казан, 1979. С. 139–168.

Молькеевские кряшены: сб. статей / отв. ред. Д. М. Исхаков. Казань: ИЯЛИ АНТ, 1993. С. 4–25.

*Мухаметшин Ю. Г.* Татары-кряшены. Историко-этнографическое исследование материальной культуры (середина XIX – начало XX вв.). М.: Наука, 1977. 184 с.

Нагайбаки (комплексное изучение группы крещеных татар-казаков). Казань: ИЯЛИ АНТ, 1995. 147 с.

*Рамазанова Д. Б.* Названия одежды и украшений в татарском языке в ареальном аспекте. Казань: Мастер-Лайн, 2002. 354 с.

*Рамазанова Д. Б.* Термины родства и свойства в татарском языке. Казань: Татар. кн. изд-во, 1991. 192 с.

*Ercan Alkaya, Zoya Kirillova*. Kreşin Tatar Türkçesi (Dil, Tarih, Kültür). İstanbul: Kesit Yay., 2018. 670 s.

# ЛЕКСИЧЕСКИЕ ОСОБЕННОСТИ ГОВОРОВ ТАТАР-КРЯШЕН

**Зоя Николаевна Кириллова,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
zkirillova@yandex.ru.

**Эржан Алкая,**
Университет Фырат,
Турция, г. Элязыг,
ealkaya16@gmail.com.

В статье представлены результаты исследования лексических особенностей говоров татар-кряшен. Большинство представителей этой этноконфессиональной группы живет на территории Республики Татарстан, отдельные группы – в соседних Республике Башкортостан, Удмуртии, Челябинской, Кировской и Самарской областях. Говоры кряшен, живущих на столь обширной территории, имеют отличительные особенности, в системе обычаев-обрядов также наблюдаются некоторые различия. В зависимости от места проживания, языковых и разговорных особенностей говоры кряшен принято делить на 5 групп: кряшены Заказанья, Нижнего Прикамья, нагайбаки, чистопольские, молькеевские, или нагорные, кряшены. Первые три группы относятся к среднему диалекту татарского языка, а говоры чистопольских и молькеевских кряшен ближе к западному диалекту. В статье систематизирован материал по лексике говоров татар-кряшен, совпадающей с лексикой других татарских говоров, а также имеющей свои особенности.

По мнению исследователей, в говорах кряшен сохранились древние элементы. Особое значение имеет лексический пласт, характерный только для говоров крещеных татар. В статье проанализированы термины родства, наименования одежды и названия украшений.

**Ключевые слова:** татары-кряшены, крещеные татары, говоры, лексические особенности, термины родства, наименования одежды, названия украшений.